Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Янсуар авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Янсуар авыл җирлеге
Нырсуар торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

29 ноябрь, 2022 ел № 3

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Янсуар авыл җирлегенең Нырсуар торак пунктында 2022 елның 29 ноябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 74 (җитмеш дүрт).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 38 (утыз сигез).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 38 (утыз сигез).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2023 елда Нырсуар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларны, 5 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрне, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми кулланылыштагы урыннарны төзекләндерү»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Янсуар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Янсуар авыл җирлеге башлыгы В.Н. Таланов